**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**«28» март, 2018 ел** **№ 203**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 31 мартындагы 49 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2017 елның 13 апрелендәге 138 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» нигезләмә (2017 елның 13 октябрендәге 168 номерлы кертелгән үзгәрешләр белән) нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 31 мартындагы 49 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибе турындагы нигезләмәнең II бүлегенең 2.9 пунктындагы 3 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәттән азат ителгән муниципаль хезмәткәр эштән азат ителгән көнне муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан чыгарыла. Муниципаль хезмәткәр вафат булган (һәлак булган) яисә муниципаль хезмәткәр хәбәрсез югалган дип танылган яисә аны законлы көченә кергән суд карары белән үлгән дип игълан ителгән очракта, муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәткәрләр реестрыннан үлгән (һәлак булган) көннән икенче көнендә яисә суд карары законлы көченә кергән көндә чыгарыла».

1.2. Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфалары

реестрының 1 бүлегенең 3 пунктындагы 4 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль район башкарма комитетының мөстәкыйль бүлеге башлыгы урынбасары;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин